Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы ш.т.б. Байлар Сабасы гомуми үсеш бирүче төрдәге Саба 4 нче “Кыңгырау” балалар бакчасы мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

# «Мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә кейс- ысулы»



**Кейс-ысулы** – ул чын яки уйдырма вакыйгаларны кулланып, кыска вакыт аралыгында белем бирүнең интерактив алымы. Бу алым катнашучыларның яңа сыйфатларын, осталыкларын үстерә.



*casus* *(латин)*– **буталган, гадәттән тыш очрак;**

*case* (инглиз) – **портфель, чемоданчик.**




# Кейс ни өчен кирәк?

Кейс - тәҗрибә уртаклашу, үзеңне вакыйгадагы кеше урынына куеп карау, чынбарлыкны яки уйдырманы кабул итү, чишү юлларын эзләү, башкалар ялгышыннан үзеңә дөрес юл сайларга өйрәнү өчен кирәк.




# Таләпләре, шартлары:

- төгәл куелган максатка туры килү;
- тиешле дәрәҗәдә кыенлыкларга да ия булу;
- типик вакыйгаларны иллюстрацләү;
- аналитик фикерләүне үстерү;
- бәхәс тудыру;
- берничә җавап табу.




# Төзелеше:

- вакыйга, проблема чын тормыштан алына;
- вакыйгаларның контекстында  тарихи, хронологик урыннары, катнашучылары билгеле ;
- комментарик вакыйгаларны автор тәкъдим итә;
- кейс белән эшләү өчен сораулар, биремнәр;
- кушымталар;




**Кейс технологияләр процессында балалар:**

- аралашу вакытында кирәкле мәгълүматны алалар;
- үзләренең ниятләрен башкалар фикере белән чагыштыралар;
- үз фикерләрен дәлилләргә өйрәнәләр;
- сорау бирергә, бәхәстән читтә калмаска кирәклеген аңлыйлар;
- кирәк вакытта ярдәм кабул итәргә өйрәнәләр.




**Кейс-технологияләр коммуникатив күнекмәләр формалаштыралар:**

- балалар команда белән эшләргә;
- өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашырга ;
- килеп чыккан каршылыклы, конфликтлы вакыйгаларга адекват рәвештә карарга ;
- уен белән тормыш арасында үзара элемтә оештырырга;
- реаль тормышта , өлкәннәрдән башка гына белем алырга өйрәнәләр;



# Кейс технология төрләре:

- Конкрет вакыйгаларны анализлау, уен проектлау.
- Ситуацион- рольле уен.
- Фото-кейс.
- Кейс иллюстрация.



# Кейс конкрет вакыйгаларны анализлау. Уен проектлау

**Тема: «Телефоннан сөйләшү» (зурлар төркеме)**
**Максат:** аралашу кагыйдәләре һәм нормалары турында булган белемнәрен ныгыту , сөйләм культурасын үстерү, көндәлек тормышта әдәби сөйләмне куллану ихтыяҗы тәрбияләү.

Илдус телефоннан Айнурга шалтырата. Телефон трубкасын Айнурның әтисе ала.

- Айнурны чакырыгыз.
- Айнур өйдә түгел. Ә мин кем белән сөйләшәм?
- Әй ,ярар, соңрак шалтырырмын.

**Сораулар:**

Илдусны әдәпле һәм тәрбияле бала дип әйтеп буламы?
Ни өчен?
Илдус телефоннан сөйләшә беләме?
Малай аралашу кагыйдәләренең кайсысын үтәмәде?
ә сез ничек аралашыр идегез? Үрнәк күрсәтегез әле.

# Ситуацион- рольле уен.

**Тема:** *« Кибеттә»*

**Максат:** 1,2,3, 4,5 цифрлары белән предметларның бәйләнешен өйрәнүне дәвам итү, балалар арасында дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү

**Текст:** Балалар « Кибетле»(сюжетлы – рольле уен) уйныйлар . Алар кулдан ясаган «акчаларга» язылган санга туры килердәй предметларны «кибеттән» алып китәләр. Мәсьәлән: «Минем куяныма 3 кишер кирәк, менә сезгә 3 саны язылган акча». Сатучы «акчаны» ала, тикшерә, кишерләрне бирә.«Рәхмәт! Тагын килегез», дип озата.

Яңа килгән кыз - Алсу саннарны танымый. Аның чираты җиткәч, ни эшләргә белмәү сәбәпле , ул барлык предметларны сумкасына сала башлый. Балалар көлә башлый, Алсу үпкәли. **Ә сез сатучы ролендә булсагыз ни эшләр идегез?**



## «Фото – кейс» ысулы.

**Фото** « Айдар аш ашамый»

**Максат:** беренче ашны ашап бетерү мотивациясе булдыру.

**Текст**: Балалар бакчасында төшке аш вакыты. Поварлар бик тырышып тәмле һәм файдалы аш пешергәннәр. Ашның хуш исе бакча буйлап таралган иде. Тәрбияче ярдәмчесе аш алып керде. Балалар өстәл тирәли утырдылар һәм аш ашый башладылар. Айдар гына ашка кагылмады.

Малай ни өчен аш ашамый икән?

Аш нәрсәсе белән файдалы?

Айдар урынында син нишләр иден?




## «Кейс-иллюстрация» ысулы

**Тема:** Кунакта

**Максат:** Балаларны кунакчыл , тәртипле, әдәпле булырга, кунакларга, дусларыңа хөрмәт күрсәтергә өйрәтү; үзеңне әдәпле тоту күнекмәләрен тәрбияләү, башкалар үрнәгендә үзләренең ялгышларын төзәтү.

**Сораулар:**

Рәсемдә ни күрәсез?
Кемнәр кунаклар, ә кем хуҗа?
Бу балалар нигә бик аптыраган, нигә читтә торалар?
Малайның ялгышы нидә?
Аны киләчәктә кунакка чакырырлармы икән?
Мондый очракта сез ни эшләр идегез?



# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

